ГЛАВА КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

д. Канаш

17.11.2015　　　　　　　　№1

«2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында»

Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар уздыру юлы белән 2016 елга бюджет проекты буенча фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында ” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә һәм "Канаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. “Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советы карарының “2016 нчы елга Канаш авыл җирлегенең бюджеты турында”гы карары проекты буенча халык алдында тыңлаулар билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 27 ноябрендә 15.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

2.3. үткәрелү урыны - Канаш авылы, Үзәк ур., 7 йорт; Канаш авыл клубында;

2.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен чыгыш ясау хокукы белән гариза бирергә мөмкин булган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелгән адрес

- Канаш авылы, Үзәк урамы, 4 йорт, Канаш авыл җирлегенең башкарма комитеты секретаре Степанова В.Н. (эш көннәрендә - 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.5. җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты - 2015 елның 20 ноябренә кадәр (тел 36-7-45).

3. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең башкарма комитетына

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Советының "2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге бюджеты турында" гы карары проекты буенча ачык тыңлауларны гамәлдәге законнар һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2.гавами тыңлауларны үткәрү нәтиҗәләре буенча Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советына халык алдында тыңлаулар беркетмәсе, халык алдында тыңлаулар тәкъдимнәре, халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук 2016 елга Канаш авыл җирлеге бюджеты проектын тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны, "Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең 2016 елга бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советының карар проектын "Волжская новь" район газетасында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков